Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

16 июнь 2015 ел №473

Әлмәт муниципаль районы карамагында исәпләнүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары кулланылуы өчен билгеләнгән милекне формалаштыру, кертү һәм исемлекне бастырып чыгару тәртибен раслау

Әлмәт муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек инфраструктурасы булдыручы, урта һәм кече эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга милек ярдәме күрсәтү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән №131 Федераль Законның “Россия Федерациясендә үзиадарә оешмаларының гомуми тәртибе” ндә каралган 15 маддәсе, 2007 елның 24 июлендәге №209-ФЗ “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” турындагы законга нигезләнеп, Әлмәт муниципаль районы прокуратурасының 2015 елның 21 апрелендәге №498 нче күрсәтмәсен караганнан соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Әлмәт муниципаль районы милегендәге, өченче зат хокукларыннан азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына тапшырылырга тиешле муниципаль милекне (җир участокларыннан тыш) формалаштыру тәртибен расларга (Кушымта №1 ).

2. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына Әлмәт муниципаль районы милегендәге, өченче зат хокукларыннан азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына тапшырылырга тиешле муниципаль милек (җир участокларыннан тыш) исемлеген расларга.

3.Район Советы аппараты юридик бүлегенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырырга, “Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгының рәсми хокукый мәгълүмат порталы” һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар югарыда күрсәтелгән рәсми чыганакларда бастырганнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, торак–коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (А.И.Верия) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Н.М. Хәйдәрова

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2015 елның
16 июнендәге № 473
карарына кушымта №1

Әлмәт муниципаль районы карамагында исәпләнүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары кулланылуы өчен билгеләнгән, өченче зат хоукларыннан азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына тапшырылырга тиешле муниципаль милекне (җир участокларыннан тыш) формалаштыру, кертү һәм исемлекне бастырып чыгару тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге нигезләмә Әлмәт муниципаль районы карамагында исәпләнүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары кулланылуы өчен билгеләнгән, өченче зат хокукларыннан азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына тапшырылырга тиешле муниципаль милекне (җир участокларыннан тыш) (алга таба – исемлек) бушлай, озак вакытлы, шул ук вакытта льготалы шартларда формалаштыру, кертү һәм исемлекне бастырып чыгару тәртибен билгели.

1.2. Исемлекне формалаштыруны муниципаль милек буенча вәкаләтле орган–Әлмәт муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы башкара (алга таба – вәкаләтле орган).

1.3. 2008 елның 22 июлендәге №159-ФЗ “Россия Федерациясе субъектларының дәүләт яки муниципаль милке булып исәпләнгән торак булмаган милекне урта һәм кече эшмәкәрлек субъектларын арендага бирү, шәхси милек буларак читләштерелү, Россия Федерациясе дәүләт актларының кайберләренә үзәрешләр кертү турында”гы законның 2.1 бүлеге, 9 маддәсендә каралган очраклардан башка исемлеккә кертелгән муниципаль милек шәхси милек буларак читләштерелергә тиеш түгел.

## 2.Исемлекне формалаштыру тәртибе

2.1. Исемлек әлеге тәртипнең 2.2 нче пунктында каралган, муниципаль унитар предприятие яки муниципаль оешмага беркетелмәгән, шулай ук өченче зат хокукларыннан азат булган Әлмәт муниципаль районы казнасы мөлкәте булып саналган милектән формалаша.

2.2. Исемлеккә өченче зат хокукларыннан азат булган, торак булмаган биналар, корылмалар, төзелмәләр, шулай ук җиһазлар, махсус транспорт чаралары кертелә.

2.3. Исемлектән чыгару түбәндәге очракларда эшләнә:

-куллану вакыты тәмамлану;

-милекне югалту;

-милекнең саны һәм сыйфаты югалу нәтиҗәсендә куллануга яраксыз булуы;

-милекнең куелган тәртиптә Федераль, Татарстан Республикасы яки Татарстан Республикасының “Әлмәт шәһәре” муниципаль берәмлегенә тапшырылуы;

-әлеге объектның муниципаль ихтыяҗ өчен кирәк булуы;

-килешү төзү максаты белән өч тапкыр аукцион сатулар уздырылганнан соң да муниципаль милекне арендага алу турында законда каралганча килешүләр төзелмәгәндә, әлеге милеккә карата аны киләчәктә ничек куллану буенча карар кабул ителә.

2.4. Милек исемлеге Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана.

## 3. Исемлекне алып бару тәртибе

3.1. Исемлек вәкаләтле орган тарафыннан электрон рәвештә алып барыла.

3.2.Исемлек түбәндәге мәгълүматларны туплаган реестрдан гыйбарәт:

-тәртип буенча номер;
-милекнең реестр номеры;
-муниципаль милекнең исеме;
-милекнең идентификацион мәгълүматлары (кадастр номеры һәм башкалар);
-милекнең характеристикасы (мәйданы, этажы);
-муниципаль күчмә булмаган милекнең урнашу урыны;
-милекнең максатчан билгеләнеше (милек максатчан кулланылмаган очракта исемлектә аны кулланылуның мөмкин булган очраклары күрсәтелә)
-милеккә карата булган чикләүләр турында мәгълүмат.

## 4. Исемлекне бастырып чыгару тәртибе

4.1.Исемлек һәм аңа кертелгән үзгәрешләр “Альметьевский вестник” газетасында, шулай ук “Интернет” челтәре, Әлмәт муниципаль районы сайтында үзгәрешләр кертелгәннән соң 10 көн вакыт эчендә бастырылып чыгарылырга тиеш.

Муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Н.М. Хәйдәрова